Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

**2021 елның 13 декабре** **№ 77**

**«Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләргә кертү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 12 декабрендәге 150 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 30 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә җирләрне махсус сакланылучы җирле әһәмияттәге территорияләр җирләренә кертү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 12 декабрендәге 150 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга:**

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә.Габидуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Башлыгы,
муниципаль район Советы рәисе Н.А.Вазыйхов